РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның «28» октябрь 444 №

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге «Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның һәм инвалид балаларның туклануын оештыру турында» 446 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 39, 79 статьясы таләпләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге «Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның һәм инвалид балаларның туклануын оештыру турында» 446 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге «Әлки муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның һәм инвалид балаларның туклануын оештыру турында» 446 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында билгеләргә:

– бер тапкыр кулланыла торган көнлек кайнар ризыкның уртача бәясе 7дән 11 яшькә кадәр бер укучыга-52,85 сум, 11 яшьтән 18 яшькәчә балалар өчен - 32 сум;

– ике тапкыр кулланыла торган көнлек кайнар ризыкның уртача бәясе 7дән 11 яшькә кадәр бер укучыга- 64 сум, 11 яшьтән 18 яшькәчә балалар өчен - 38 сум.

11 яшьтән 18 яшькә кадәр балалар өчен туклану бәясе 7 сум 70 тиен күләмендә җирле бюджет акчалары, ата-аналар түләве исәбенә аерма түләнә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов